УДК 82.09

***Ә.Х. Алеева***

# Г. ТУКАЙ ИҖАТЫ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ (Ризван һәм Фәрханә Алушилар мисалында)

В статье рассматривается как в просторах Сибири и на Востоке страны (в городах Ачинск, Чита, Иркутск, Благовещенск, Хабаровск) среди татарского населения получили быстрое распространение и признание стихи Габдуллы Тукая. В этом деле немалую роль сыграла просветительско-педагогическая деятельность современников поэта – педагога и журналиста Ризвана Алуши (Ибрагимова) и его супруги – педагога и публициста Фарханы Алуши. Освещается отношение Р. Алуши к творчеству Г. Тукая в его статьях на страницах таких газет, как «Сибирия», «Тормыш». В педагогико-методической сфере Ризван и Фархана Алуши широко используют творчество Тукая, часто обращаются к его стихам. Р. Алуши глубоко переживает смерть поэта. В его статье «Габдулла әфәнде Тукаев», написанная под впечатлением данного события, обобщенно отображается эта трагедия как общее горе всего татарского народа. Им высоко оценена гениальность поэта, его талант, подчеркивается значение его бесценного творчества для татарской литературы. Многогранная деятельность супругов Алуши способствовала широкой рекламе творчества Г. Тукая среди татар данного региона.

**Ключевые слова:** творчество Габдуллы Тукая, Ризван Алуши (Ибрагимов), Фархана Алуши, просветительская деятельность. «Сибирия», «Тормыш»

This article examines how Gabdulla Tukay's poetry quickly spread and gained recognition among the Tatar population in the vast expanses of Siberia and the east of the country (in the cities of Achinsk, Chita, Irkutsk, Blagoveshchensk, and Khabarovsk). The educational and pedagogical work of the poet's contemporaries, teacher and journalist Rizvan Alushi (Ibragimov) and his wife, teacher and publicist Farhani Alushi, played a significant role in this process. R. Alushi's attitude toward Tukay's work is highlighted in his articles in newspapers such as "Sibiriya" and "Tormish". In their pedagogical and methodological work, Rizvan and Farhani Alushi widely utilize Tukay's work and frequently refer to his poems. R. Alushi deeply mourned the poet's death. His article, "Gabdulla Tukayev", written in the wake of this event, sums up this tragedy as a shared grief for the entire Tatar people. He highly praised the poet's genius and talent, emphasizing the importance of his invaluable work for Tatar literature. The multifaceted activities of the Alushi couple contributed to the widespread promotion of G. Tukai's work among the Tatars of the region.

**Keywords:** Gabdulla Tukay's work, Rizvan Alushi (Ibragimov), Farkhan Alushi, educational activities. "Siberia", "Tormysh"

Билгеле булганча, бөек Тукаебызның тавышы, матбугатта басылган әсәрләре чыккан көне белән үк халык күңелен җәлеп итә, аның авазы Россиянең татарлар яшәгән барлык почмакларында да яңгырый. Чөнки аның язганнары халкыбызның рухына, тормышына муафикъ, якын, иҗаты татар әдәбиятының киләчәге, тәрәккыйсы

хакында өметләр тудыра. Халыкчан, җанлы шигырьләре татарның гасырлар буе тутыккан күңелләрен ялтырата, яктырта. Шуңа да ул бик тиз арада үзен милләтенә таныта. Бу хакта мәгълүматлар вакытлы матбугатта да чагылыш тапкан, күпсанлы замандашларының хатирәләрендә, истәлек язмаларында әйтелгән. Шундый чордашларыннан Ерак Себердә (Ачинск, Чита, Икрутск, Благовещенск, Хабаровск һ. б. шәһәрләрдә) эшләгән мөгаллим, педагог, журналист һәм ниһаять мәгърифәтче Ризван Алуши һәм аның җәмәгате Фәрханә Алушилар да бар. Сүз алар турында, аларның шагыйрьгә, аның иҗатына мөнәсәбәтләре турында барачак.

Ризван Алуши (Ризван Ибраһимов) (1883–1938) Саратов губернасы Биги авылында (хәзерге Пенза өлкәсе Неверкин районы) туа. Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә белем ала (1896–1904). Казанның алдынгы шәкертләреннән, шәкертләрне берләштерү, мәдрәсәләрдә укытуны яңарту максаты белән төзелгән «Әлислах» комитететының Себер шәһәрләрендәге мөгаллимнәр, мәдрәсәләр белән элемтә урнаштыручысы сыйфатында Себергә укытучы булып китә. Ачинск (1905–1907), Чита (1907–1912), Хабаровск (1912–1914), Чиләбе (1915–1917) шәһәрләрендә мәдрәсәләрдә укыта. Укытуда яңа ысул-методлардан файдалана. Ачинск шәһәрендә хатын-кызлар мәктәбе ача, кызлар белән малайларны бергә укыта башлый. Р. Алуши 1906 елдан башлап татар матбугатында мәкаләләр, хикәяләр белән катнаша. «Фикер», «Казан мөхбире», «Сибирия», «Вакыт» газеталарында, «Шура» журналында Себер татарлары, мөселман уку йортларының торышы, укытучыларның тормыш шартлары турында мәкаләләре басыла. Себердә эшләгән чорда дөнья күргән күпсанлы мәкаләләрен эчтәлек ягыннан икегә бүлеп карарга була. «Сибириягә даир» (1906), «Сибирия нә халәттә» (1906), «Сибирия тәэссирате» (1915) кебек мәкаләләрендә ул Себер тарихы, аның Россиягә кушылуы, табигый байлыклары, биредә яшәүче татарларның этник үзенчәлеге, көнкүреше турында яза. Икенче төр мәкаләләрендә («Сибириядә ир вә кыз балалар бергә укый торган мәктәпләр» (1912), «Мәктәптә тәрбияи бәдәния илә тәрбияи рухания» (1911) һ. б.) ул мәгариф, уку-укыту методикасы, тәрбия мәсьәләләрен күтәреп чыга.

Фәрханә Алуши (Фәрханә Рәхимгәрәй кызы Бәхетгузина) (1886–1958) Себердәге Ачинск шәһәрендә хезмәткәр гаиләсендә туа, заманы өчен киң кырлы белем ала һәм соңыннан үзе дә бөтен гомерен укыту-тәрбия эшенә багышлый. 1906 елда Фәрханә Фатих Әмирханның якын дусты, фикердәше, Ачинскидагы татар мәктәбендә укытучы булып эшләүче Ризван Алушига кияүгә чыга. Шуннан соң алар, кулга-кул тотышып, инкыйлабка кадәр Себернең төрле шәһәрләрендә (Ачинск, Чита, Хабаровск һ. б.), ә соңыннан Чиләбедә һәм Уфада мөгаллимлек эшләрен дәвам иттерәләр.

Татар вакытлы матбугаты барлыкка килгәч, Фәрханә һәм Ризван Алушилар икесе дә, кулларына каләм алып, актив рәвештә газета-

журналларга мәкаләләр язалар. 1906 елгы «Фикер» газетасының (Уральск) 14 һәм 31 июль саннарында Фәрханә Алушиның «Сибирия хатыннарының тавышы» исемле шактый күләмле публицистик мәкаләсе басылып чыга. Бу басмада Г. Тукай актив хезмәт куйган һәм, әлбәттә, Ф. Алушиның мәкаләсе аның кулы аша үткән. Ф. Алуши Казанда чыга торган газеталарда да (мәсәлән, «Бәянелхак»та) мәкаләләре һәм нәсерләре белән еш катнаша.

Публицистик мәкаләләрендә Ф. Алуши татар мәгарифен яңача үстерү, мәктәпләр хәле, хатын-кыз азатлыгы кебек актуаль мәсьәләләрне күтәрә һәм аларның һәрберсе хакында үзенең кыю фикерен әйтә.

Ризван һәм Фәрханә Алушиларның педагогик һәм мәгърифәтчелек эшчәнлекләрен таныган, зурлаган язмалар шул чорда «Сибирия» газетасында [1; 4] яктыртыла. Мәсәлән, «Себер мөгаллиме Ризван әфәнденең юбилее мөнәсәбәте илә» дигән мәкаләдә: «1907 елда, август урталарында Ризван әфәнделәр Читага килделәр. Шул көннән башлап Ризван әфәнде мәктәп балаларына белем-тәрбия бирү белән бәрабәр, мәктәп тышында да халык арасында гыйлем таратырга тырышалар иде. Килгән елны ук Ризван әфәнде иҗтиһады илә мәктәп янында китапханә дә ачылды. Китапханәгә яше-карты ябырылып йөри башладылар. Милли әдәбият белән мәшгуль булдылар. Күбесе газета-журнал яздырып ала, өйләренә алып та китап укый башладылар, үзе укый белмәгәне кеше укыганны тыңлап тора иделәр. Янә дә Читада хатын-кызларның күзен ачучы, аларның кеше төсле дөньяга чыгып йөри башлауларына Ризван әфәнде илә рәфикасы – мөгаллимә Фәрханә ханым сәбәп булдылар. Үзләрен ирләр кәефе өчен генә ятылган дип уйлаган, өйдә тоткынлыкта саргаеп ята торган абыстайлар да бераз уяндылар. Үз кирәкләрен кайгырта башладылар.

Фәрханә ханым исә хатыннарны җыеп укытты. Өйдә генә ябылып яту ярамаганлыгын, дөньяга чыгып, ирләренә булышлык кылу кирәк икәнлеген аңлатты» [4], – дигән юллар белән очрашабыз. Әлбәттә, бу эшләр аларга җиңел бирелми, адым саен киртәләр дә булып тора.

Р. Алуши Казанда «Мөхәммәдия»дә укыган елларында Ф. Әмирхан белән сабакташ дуслар булалар, һәм бу дуслык гомерләренең азагынача дәвам итә. Алар арасында туктаусыз хат алышу, бик еш булмаса да очрашулар булып торган. Читтә йөргән дусларына хат язганда Ф. Әмирханның Г. Тукай турында әледән-әле хәбәр биреп торуы мәгълүм. Р. Алушиның Ф. Әмирхан аркылы Г. Тукай белән очрашкан, танышкан булуы да ихтимал. Һәрхәлдә үзе дә матбугатта катнашып яшәгән Р. Алуши Г. Тукайның иҗаты белән даими танышып барган. Ф. Әмирхан аңа Казанда чыккан «Әлислах» (1907–1909) газетасын Себер шәһәрләрендә тарату өчен күпләп җибәреп торган. Шул рәвешле, Алуши Г. Тукайның матбугатта дөнья күргән әсәрләрен Себер халкы арасында тарата. Тукай иҗатын мәктәп балаларына өйрәтә, милли тәрбияне Тукай әсәрләренә таянып алып бара. Үзе оештырган китапханәләрдә аның әсәрләрен булдыра.

Г. Тукайның үлемен Ризван Алуши авыр кичерә. «Сибирия» газетасының 1913 елгы 15 май санында: «Габдулла әфәнде Тукаев» дигән мәкалә язып бастыра. Биредә ул шагыйрьне гасырлар буе торгынлыкта изелеп яшәгән татар милләтенең күзен ачучы, киләчәккә өметен уятучы, рухын күтәрүче, Аллаһ тарафыннан җибәрелгән даһи, олуг зат дип бәяли.

Тукай иҗатының асылын ассызыклап, халык күңеленә якынлыгының сәбәпләренә туктала: «Ул татар милләте арасында җитлеккәнгә күрә, аларга нинди сүз әйтергә кирәк икәнен белгәнгә, ачы хәсрәтле шигырьләре милләтне уятты, моңлы шигырьләре илә кальбемезнең иң нечкә кылларына тәэсир итте. Җәһаләт йокысына талган, изелеп рухы зәгыйфьләнгән татар милләтенә яктылык, нур сибеп күзен ачты, алга барыр дөрес юлны тәгаенләде» [2], – ди.

Халыкның Тукайга мөнәсәбәтен, сөекле шагыйрьне югалтуның ачысын, фаҗигасын гомумиләштереп чагылдыра: «Рухыбызга тәэсир итә торган моңлы музыкабыздан бер кылы өзелде... ачы хәсрәтебезне җырлый-сайрый торган бер былбылыбыз очты ... Менә ул даһи, менә ул нур – инде бездән китте – Габдулла әфәнде Тукаев үлде! Шуның илә яшь татар әдәбиятының нигезеннән иң кирәкле бер терәге ауды, – дип, Тукай иҗатының әһәмиятен, татар әдәбиятындагы урынын югары бәяли. – Аның үлеме бөтен милләтнең калебен сызлатты. Чөнки ул бик аз яктырды, бик аз сайрады. Ләкин шулай да хәзер инде һичбер күздән аның нуры бетәчәк түгел, һичбер татар күңеленнән аның татлы шигырьләренең тәме китмәс. Ул үлде, ләкин милләтне кабат йокламаслык итеп уятып үлде» [2], – дип яза.

Шагыйрь үлеменә бер ел тулганда, Р. Алуши «Тормыш» газетасында күләмле мәкалә [3] бастыра. Биредә ул шагыйрь иҗатының Себердә дә киң таралышын, төрле халык катлаулары арасында яратып кабул ителүен дәлилли. Бу иҗатның мәңге актуальлеген, халыкка һәрвакыт кадерле булачагын моннан 100 елдан арттык элек үк күрә алган һәм шулай буласына чын күңелдән инанган.

Бу мәкаләсендә Ризван Ибраһимов шагыйрь иҗатының илебезнең ерак почмакларына кадәр барып җитүен тарихи факторларга бәйләп яктырта. Элек Себер яклары татарлар карашында каторга урыны, җинаятьчеләр оясы булып кына аңланган бик куркыныч җирләр булып күренсә дә, Россиядәге 1905 елгы инкыйлаб нәтиҗәсендә, мәдрәсәләр тәмамлаган татар яшьләренең дә күзләре ачылуын һәм аларның гаярь бер төркеме муллалыктан башка кәсеп эзләп, салкын Себердән һич курыкмыйча, Шәрыкка таба юл алуларын, Сибириянең төрле тарафларына күпләп килеп урнашуларын яза. Себердә укыган сыйныф барлыкка килүен дә инкыйлаб нәтиҗәсе белән бәйли. Аларның бирегә килеп татар мәктәпләре ачуын, татарча сөйләшүчеләрнең ишәюен дә искә ала. Шул рәвешле халыкка хезмәт итәргә алынган яшьләр белән бирегә татар әдәбияты да килүен, Себергә, күп булмаса да, газета-журналларның, төрле китапларның җибәрелүен һәм шул әдәбият арасында иң таралганы, иң яратып

укылганы Габдулла Тукаев әсәрләре булуын ассызыклый. Үзенең фикерләрен дәлилләү өчен мисал итеп конкрет фактлар да китерә. Мәсәлән: «Бервакыт май аенда Иркутскиның Лотфый әфәнде Исхаков илә Русиягә карап бара идек. Күңелле берәр нәрсә очрамасмы дип 3 нче класс вагоннарына чыгып йөргәндә, бер төркем узелчеләрнең (вак-төяк белән сәүдә итүчеләр) иң сөекле эше булган “карта” уеннарын ташлап, бик ихлас белән бер татарның нәрсәдер укыганын тыңлап баруларын күреп яннарына туктадык. Укыган китаплары “Әлгасрелҗәдид” журналы иде. Шунда тәмләп-тәмләп Габдулла әфәнденең “Мөридләр каберстаныннан бер аваз” дигән шигырьләрен укыйлар иде. Шуннан соң агайлар тагы берничә номер журнал күрсәтеп, һәркайсысыннан Тукай шигырьләрен яратып укыганнарын белдерделәр. Бу 1906 ел иде – димәк, тиңсез шагыйребезнең тавышы, шигырьләре чыккан көне илә ерак Сибиргә кадәр ишетелде, яңгырады» [3]. Чита шәһәренә күченеп яши башлагач (1907), китапханә мөдире буларак, Р. Алуши түбәндәге вакыйгаларны искә ала: «Читада торган чагыбызда, әдәбият сөюче яшьләр яңа чыккан китап вә рисаләләрне минем аша алдыра иделәр. Шунда иң күп сораган нәрсәләре Тукай шигырьләре була иде. Читаның картлары-яшьләре, ханым вә туташлары Габдулла әфәндене сөяләр, яратып укыйлар. Шигырь мәҗмугалары чыкканын түземсезләнеп көтәләр иде» [3]. Хәтта Благовещенск һәм Амур буйлары елның күбрәк өлешен урта Россиядән киселеп торсалар да, аларда Тукай шигырьләрен очрату мөмкин булуын, «чөнки күп кешенең йортында аның китаплары бар иде», дип, аның халык өчен бик сөекле, яратылган булуына дәлил итеп күрсәтә. Хабаровскида яшәүче милләттәшләребез арасында да Тукай шигырьләренә булган мөнәсәбәтне гади халыкның үз «теленнән әйттерә»: «1912 елның яз айларын Благовещенскида үткәрдем. Шул елны Благовещенск белән Хабаровск арасында һөнәре “карта” уйнап йөрү булган бер татарга очрадым. Танышкач ук, Тукаевның “Күңел җимешләре” исемле шигырь мәҗмугасын бирде һәм үзенең Тукай шигырьләрен сөеп укуын сөйләде» [3]. Үзе очраткан, аралашкан бик күп яшьләр һәм ханым-туташларның Тукай шигырьләрен күңелдән белүләрен, яттан сөйләүләрен һәм көйгә салып җырлауларын да яза.

Р. Алуши Габдулла Тукай язган шигырьләрнең халыкка тиз танылуын һәм яратып кабул ителүен татар халкы рухына туры килә торган булуда, татар аңларлык стильдә, акрынлап иске төшенчәләрдән саф татарчага күчүдән дә килә дип аңлата.

Тукайның үлеменә бер ел тулуга багышланган мәкаләсендә шагыйрьне сагынып язган: «Ул үлде – әмма аның мөкатдәс хезмәтләре терек, шуңа да ул милләт үскәнчә үсәр – милләт яшәгәнчә яшәр» [3], дигән шигарь рәвешендә яңгыраган сүзләр дә Тукайның замандашы, шагыйрь иҗатының бөеклеген аңлый белгән, аның талантын югары бәяләгән педагог һәм мәгърифәтче Ризван Алуши каләме белән язылган.

Үз чорында ук халык шагыйре дип танылган Г. Тукайның тиңсез талантын, әсәрләрен хөрмәт иткән Ризван һәм Фәрханә Алушилар Россиянең ерак төбәгендә – Себердә яшәгән милләттәшләребезгә мәгърифәт, әдәбият, белем таратуда үзләреннән зур өлеш кертәләр. Бер үк вакытта мәктәпләр, китапханәләр ачып, татар әдәбиятын, шул исәптән Г. Тукай әсәрләрен халыкка җиткерүдә күп тырышлык куялар. Татар вакытлы матбугатында дөнья күргән актуаль һәм кыю мәкаләләре белән дә җирле халыкны мәгърифәтле итүгә, аның милли үзаңын уятуга этәргеч бирәләр.

**Әдәбият**

1. *Биккулов И.* Сибириядә кечкенә генә юбилей // Сибирия.1913. 10 март.

2. *Ибраһимов Р.* Габдулла әфәнде Тукаев // Сибирия. 1913. 15 май.

3. *Ибраһимов Р.* Сибирия татарлары каршында мәрхүм Габдулла әфәнде Тукаев // Тормыш. 1914. 2 апрель.

4. *Мөһибуллин К.* Сибир мөгаллиме Ризван әфәнденең юбилее мөнәсәбәте илә // Сибирия. 1913. 12 май.

***Алеева Әнисә Хәниф кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре*

***Алеева Аниса Ханифовна,***
*кандидат филологических наук, старший научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*

*2450774@mail.ru*